# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге составына керүче Иске Чепья авылы торак пунктында**

2023нче елның 27 октябере, № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 271-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Иске Чепья авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Иске Чепья авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән; 50 процент күләмендә ташлама каралган - 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; 1100 сум күләмендә үзара салым кертү күздә тотыла

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Виноград урамындагы күперне төзекләндерү.

3. Җыенның нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Чепья авыл җирлеге башлыгы А. Г. Нотфуллин